Государственное автономное профессиональное

образовательное учреждение

«Мамадышский политехнический колледж»

УТВЕРЖДАЮ

Заместитель директора по ТО

_____________ А.Д. Ахметшина

«14» ноября 2025 г.

**ФОНД ОЦЕНОЧНЫХ СРЕДСТВ**

**для проведения текущего контроля и промежуточной аттестации**

**по общеобразовательной дисциплине**

**ДВ.02 Родная (татарская) литература**

по специальности

38.02.03 Операционная деятельность в логистике

2025 г.

Фонд оценочных средств разработан на основе рабочей программы общеобразовательной дисциплины и в соответствии с Федеральным государственным образовательным стандартом среднего профессионального образования по специальности 38.02.03 Операционная деятельность в логистике, приказ Минпросвещения России от 21.04.2022 N 257 (ред. от 03.07.2024) "Об утверждении федерального государственного образовательного стандарта среднего профессионального образования по специальности 38.02.03 Операционная деятельность в логистике" (Зарегистрировано в Минюсте России 02.06.2022 N 68712)

Обсуждена и одобрена на заседании предметно-цикловой комиссии общеобразовательных дисциплин

Разработала преподаватель:
__________ А.Д. Ахметшина

Протокол № 4
«11» ноября 2025 г.
Председатель ПЦК __________ Н.С. Порываева

## Практические работы

## 1 НЧЕ БҮЛЕК

**1-4 биремнәренә җавап бирегез. А тибындагы биремнәргә җавап бирү барышында, тәкъдим ителгән өч вариант арасыннан, үзегез дөрес дип уйлаган җавапны билгеләгез.**

1. М.Әгъләмовның «Учак урыннары» шигырендә кешедән, буыннардан соң калган эзне символлаштырып килгән образ:
   1) сөлге
   2) учак урыны
   3) учак

2. Х.Туфанның «Кайсыгызның кулы җылы?» шигырендә лирик геройга хас сыйфатларны чагылдыручы вариантны билгеләгез:
   1) тормыш фаҗигасеннән, хәсрәттән арынып, мәхәббәт, бәхет көтүче
   2) илдәге тәртипләргә каршы чыгучы бунтарь
   3) яшәү кыйбласын югалткан шәхес

3. Ф.Кәрим иҗат иткән «Кыр казы» әсәренең жанрын билгеләгез:
   1) сәяси лирика
   2) гражданлык лирикасы
   3) пейзаж лирикасы

4. «*Кеше булса, эшләр эше булсын, / Тормышының булсын мең яме. / Изге хисе булсын күңелендә, / Ә җанында һәрчак ил гаме*» юллары кайсы шагыйрьнең нинди шигыреннән алынган:
   1) И.Иксанова «Кеше булса»
   2) С.Сөләйманова «Кеше»
   3) С.Сөләйманова «Кеше булса»

**5-8 биремнәренә бер сүз яки сүзтезмә белән генә җавап бирегез. Төшенчәне БАШ хәрефләр белән языгыз, бернинди тыныш билгеләре яки символлар куймагыз, ике яки өч сүз булган очракта, алар арасында буш ара (пробел) калдырыгыз. Җавапны язганнан соң нокта куймагыз. Җавап саннар белән язылган очракта саннар арасында буш ара (пробел) калдырмагыз, инструкциядә язылганны игътибар белән укыгыз. Әсәр исемнәрен язган вакытта да тыныш билгеләре куймагыз.**

5. Р.Фәйзуллинның «Көзге яңгыр» шигыреннән алынган «*Торналар китеп бара. / Кош канатлары орынгач / Болытларның күңеле тулды*» юлларында сүзнең гадәти тәртибе үзгәрүгә бәйле стилистик фигура:

Җавап: _______________

6. Шигырь һәм аның авторын туры китереп тәңгәлләштерегез:

| | |
|---|---|
| А) «Тамыр көлләре» | 1) Роб.Әхмәтҗанов |
| Ә) «Ирек» | 2) Зөлфәт |
| Б) «Елганың борылган төшендә» | 3) М.Җәлил |

Җавап:________________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

7. Тәкъдим ителгән исемлектән шагыйрьләрне иҗатка килү эзлеклелегендә урнаштырыгыз:

1. М.Әгъләмов;
2. И.Иксанова;
3. Г.Тукай.

Җавап:_______________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

8. Роб.Әхмәтҗановның «Югалган көн» шигыреннән алынган «*Бүген мине таптап узды көнем, / Тик үземнән эзлим сәбәпләр*» юлларында кулланылган тел-сурәтләү чарасы. «Сынландыру», «Эпитет», «Синоним» арасыннан тиешлесен сайлап алып языгыз:

Җавап: ______________

## 2 НЧЕ БҮЛЕК

| |
|---|
| **9 – 12 биремнәренә җавап бирегез. А тибындагы биремнәргә җавап бирү барышында, тәкъдим ителгән өч вариант арасыннан, үзегез дөрес дип уйлаган җавапны билгеләгез.** |

9. Г.Кутуйның эпистоляр стильдә иҗат ителгән әсәрен күрсәтегез:

1) «Тапшырылмаган хатлар»
2) «Хәят»
3) «Сагыну»

10. Н.Фәттах иҗат иткән «Итил суы ака торур» романының жанр төре:

1) психологик роман
2) тарихи роман

3) роман-эпопея

11. Т.Миңнуллинның «Дуслар җыелган җирдә» драмасында автор тәнкыйте юнәлдерелгән сыйфат:

1) икейөзлелек
2) саранлык
3) битарафлык

12. А.Гыйләҗевның «Өч аршын җир» повестенда «*Өч аршын җир сорыйсыңмы? Кадерле ул туган җир! Өч аршын җир! Күп сорыйсың син!*» юллары кемгә карата әйтелә?

1) Шәмсегаян
2) Мирвәли
3) Шәрифҗан

**13-16 биремнәргә бер сүз яки сүзтезмә белән генә җавап бирегез. Төшенчәне БАШ хәрефләр белән языгыз, бернинди тыныш билгеләре яки символлар куймагыз, ике яки өч сүз булган очракта, алар арасында буш ара (пробел) калдырыгыз. Җавапны язганнан соң нокта куймагыз. Җавап саннар белән язылган очракта саннар арасында буш ара (пробел) калдырмагыз, инструкциядә язылганны игътибар белән укыгыз. Әсәр исемнәрен язган вакытта да тыныш билгеләре куймагыз.**

13. Ф.Яруллинның «Җилкәннәр җилдә сынала» повестенда авыр язмышка дучар булган төп геройның исемен языгыз:

Җавап: _______________

14. Тәкъдим ителгән хронотопны һәм алар чагылыш тапкан әсәр исемнәрен тәңгәлләштерегез. Икенче баганадан беренче баганадагы хронотопка туры килгән әсәрләрне күрсәтегез.

Хронотоп:
А) Карачура авылы;
Ә) Казах далалары;
Б) Юлкотлы авылы.

Әсәр исеме:
1. Ә.Еники «Әйтелмәгән васыять»
2. А.Гыйләҗев«Өч аршын җир»
3. Г.Ибраһимов «Казакъ кызы».

Җавапта үзегез дөрес дип уйлаган җавап санын таблицадагы хәрефләргә туры китереп куегыз:

| А | Ә | Б |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| | | |

Җавап: ________________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

15. Тәкъдим ителгән исемлектән әсәрләрне күләме үсә бару тәртибендә эзлеклелеккә салыгыз:

1. «Өч аршын җир»
2. «Шәфигулла агай»
3. «Таң җиле»

Җавап: ___________________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

16. «Психологизм», «Тарихи роман», «Сатира» төшенчәләре арасыннан «Әйтелмәгән васыять» әсәрендәге Акъәбинең кичерешләрен сурәтләү барышында Ә.Еники кулланган алымны сайлап алып языгыз:

Җавап: ___________________

## 3 НЧЕ БҮЛЕК

**17.1 һәм 17.2. биремнәренә 5-10 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән эзлекле җавап таләп ителә. Биремнең номерын күрсәткәннән соң, БЕРСЕН генә сайлап алып җавап языгыз. Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез.**

17.1. Ә.Еникинең «Әйтелмәгән васыять» әсәреннән өзекне тыңлагыз һәм «*Аккилен үлмәде ул, китте генә... Китте генә... Кайтыр, насыйп булса кайтыр...*» юлларына игътибар итегез. Миңлебай картның бу сүзләре аша укучыга нинди фикер җиткерелә?

17.2. Р.Мөхәммәтшинның лирик героена нинди сыйфатлар хас?

# ҖАВАПЛАР

## Ачык һәм ябык тестларга җаваплар

| Биремнең саны | Җавабы |
|---|---|
| 1 | 2 |
| 2 | 1 |
| 3 | 2 |
| 4 | 1 |
| 5 | ИНВЕРСИЯ |
| 6 | 231 |
| 7 | 312 |
| 8 | СЫНЛАНДЫРУ |
| 9 | 1 |
| 10 | 2 |
| 11 | 1 |
| 12 | 2 |
| 13 | ФӘНИЯР |
| 14 | 231 |
| 15 | 213 |
| 16 | ПСИХОЛОГИЗМ |

**Киңәйтелгән җавапларны (5-10 җөмлә күләмендә) бәяләү критерийлары**

5-10 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән җавапны таләп итә торган бирем. Җавапка билгеләнгән күләм шартлы, ул сорауның катлаулылыгына һәм эчтәлегенә бәйле. Укучы сорауга эчтәлеге ягыннан тулы җавап язарга, әмма үз җавабын мөмкин булган кадәр кыска формалаштырырга тиеш.

| Критерий | Балл |
|---|---|
| **1. Фикер тирәнлеге һәм җавапның дәлилләнгән булуы** | |
| а) укучы биремнең үзенчәлегенә төшенгән: сорауны аңлап җавап биргән, автор позициясен ачкан, үз фикерен дәлилләгән, фактик хаталар юк / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштырган | **2** |
| б) укучы сорауга җавап бирә, ләкин җавабын нигезләп бетерә алмый / яки җавабын әсәрнең кыскача эчтәлеген сөйләү белән генә чикли, җавап хаталы һәм төгәл түгел / яки җавапта бер-ике фактик хата күзәтелә / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштырып җиткермәгән | **1** |
| в) укучы сорауга бөтенләй җавап бирмәгән / яки эчтәлеге ягыннан сорауга туры килми торган җавапны язган / яки 3 һәм аннан да күбрәк фактик хата ясалган / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштыра алмаган | **0** |
| **2. Җавапның сөйләм нормаларына туры килүе** | |
| а) Җавапта бер генә сөйләм хатасы бар | **1** |
| б) җавапта сөйләм хаталары бердән артык | **0** |
| **Иң югары балл** | **3** |

## 1 НЧЕ БҮЛЕК

| |
|---|
| **1-4 биремнәренә җавап бирегез. А тибындагы биремнәргә җавап бирү барышында, тәкъдим ителгән өч вариант арасыннан, үзегез дөрес дип уйлаган җавапны билгеләгез.** |

1. Р.Фәйзуллин иҗат иткән «Җаныңның ваклыгын…» әсәрендә автор югары күтәргән сыйфат:
   1) кеше рухының бөеклеге
   2) кеше җанының ваклыгы
   3) сентиментальлек

2. Р.Гаташ иҗатында өстенлек алган иҗат принциплары:
   1) романтик
   2) реалистик
   3) дини

3. И.Юзеев иҗат иткән «Өчәү чыктык ерак юлга» әсәренең жанры:
   1) нәсер
   2) гражданлык лирикасы
   3) поэма

4. Р.Харисның «Алтын төрән» шигырендә кешенең олылыгын, акыл мөмкинлекләрен югары күтәргән образ:
   1) алтын төрән
   2) Кояш
   3) Җир

| |
|---|
| **5 – 8 биремнәренә бер сүз яки сүзтезмә белән генә җавап бирегез. Төшенчәне БАШ хәрефләр белән языгыз, бернинди тыныш билгеләре яки символлар куймагыз, ике яки өч сүз булган очракта, алар арасында буш ара (пробел) калдырыгыз. Җавапны язганнан соң нокта куймагыз. Җавап саннар белән язылган очракта саннар арасында буш ара (пробел) калдырмагыз, инструкциядә язылганны игътибар белән укыгыз. Әсәр исемнәрен язган вакытта да тыныш билгеләре куймагыз.** |

5. Лирикада автор образын, автор аңын белдерүче ысулларның берсе; әсәрдә уй-хисләре, эчке халәте чагылыш тапкан, шагыйрьнең хисләреннән тыш, күпчелек кешеләргә хас уй-кичерешләрне гәүдәләндерүче, бәян итүче образ:

Җавап: _____________

6. Әдәби әсәр һәм аның жанрын туры китереп, тәңгәллекләр урнаштырыгыз.

| | |
|---|---|
| А) «Әйткән идең» | 1) гражданлык лирикасы |

| | |
|---|---|
| Ә) «Гашыйклар тавы» | 2) күңел лирикасы |
| Б) «Кошмы? Колмы?» | 3) поэма |

Җавап: _________________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

7. Тәкъдим ителгән исемлектәге шагыйрьләрне иҗатка килү эзлеклелегендә урнаштырыгыз:

1. И.Юзеев
2. Р.Аймәт
3. Г.Тукай

Җавап: _________________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

8. Равил Фәйзуллинның «Җаныңның ваклыгын...» әсәре кайсы әдәби төргә карый? «Шигырь», «Лирика», «Гражданлык лирикасы» төшенчәләре арасыннан сайлап алып языгыз:

Җавап: _________________

## 2 НЧЕ БҮЛЕК

**9 – 12 биремнәренә җавап бирегез. А тибындагы биремнәргә җавап бирү барышында, тәкъдим ителгән өч вариант арасыннан, үзегез дөрес дип уйлаган җавапны билгеләгез.**

9. Ш.Хөсәеновның «Әни килде» драмасында ак күлмәк образы нинди вазифа үти:

1) Ананың эчке матурлыгын, күңел аклыгын ачарга ярдәм итә
2) балаларның эчке матурлыгын, күңел аклыгын ачарга ярдәм итә
3) вакыйгаларның бару урынын күрсәтә

10. Ә.Еникинең сугыш темасына язылган әсәрләренә хас үзенчәлек:

1) сугыш вакыйгаларын җентекләп тасвирлаудан бигрәк, шул вакыйгалар чолганышындагы геройларның эчке кичерешләрен сурәтләү
2) сугыш вакыйгаларын реалистик алымнар ярдәмендә тасвирлау
3) тоткыннар язмышын сурәтләү

11. Г.Исхакыйның «Остазбикә» әсәре нинди әдәби төргә карый?

1) эпик төр
2) повесть

3) психологик повесть

12. Г.Рәхимнең «Идел» повестенда әлеге сүзләрне кем әйтә?
*Минем күңелем тагын Иделгә омтылды, мин тагын бер ай элек ташлап киткән Идел ярларын сагына башладым. Ахрысында чыдамадым, җәйнең актык көннәрен ялгызлыкта бәйрәм итәр өчен, пароходка утырып, кире җәй үткәргән җиремә киттем»*.

1) Рабига
2) Ильяс
3) Вәлид

**13-16 биремнәргә бер сүз яки сүзтезмә белән генә җавап бирегез. Төшенчәне БАШ хәрефләр белән языгыз, бернинди тыныш билгеләре яки символлар куймагыз, ике яки өч сүз булган очракта, алар арасында буш ара (пробел) калдырыгыз. Җавапны язганнан соң нокта куймагыз. Җавап саннар белән язылган очракта саннар арасында буш ара (пробел) калдырмагыз, инструкциядә язылганны игътибар белән укыгыз. Әсәр исемнәрен язган вакытта да тыныш билгеләре куймагыз.**

13. Г.Исхакыйның Галимә, Вахид, Сәгыйдә образларына бәйле гаилә тарихын бәян иткән повесте:

Җавап: ________________

14. Тәкъдим ителгән образны һәм ул чагылыш тапкан әсәр исемен тәңгәлләштерегез. Икенче баганадан беренче баганадагы образга туры килгән әсәрне сайлап алыгыз.

Образ:
А) Вәлид
Ә) Шакирҗан
Б) Хәсән

Әсәр исеме:
1. Ә.Еники «Ана һәм кыз»
2. Г.Рәхим «Идел»
3. Г.Исхакый «Җан Баевич»

Җавапта үзегез дөрес дип уйлаган җавап санын таблицадагы хәрефләргә туры китереп куегыз:

| А | Ә | Б |
|---|---|---|
| | | |

Җавап: _________________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

15. Тәкъдим ителгән исемлектән Ә.Еникинең «Ана һәм кыз» хикәясендәге геройларны әсәр сюжетында катнашу күләме үсә бару тәртибендә эзлеклелеккә салыгыз:

1. Маһирә
2. Хәсән
3. Рәхилә

Җавап: ________________

ИНСТРУКЦИЯ: Биремнең җавабы булып, саннар тезмәсе генә килә ала. Җавапны буш ара калдырмыйча, өтер яки башка символларсыз языгыз.

16. «Кыйтга», «Әни килде», «Җан Баевич» әсәрләре арасыннан комедия үрнәген сайлап алып языгыз:

Җавап: ________________

## 3 НЧЕ БҮЛЕК

| |
|---|
| **17.1 һәм 17.2. биремнәренә 5-10 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән эзлекле җавап таләп ителә. Биремнең номерын күрсәткәннән соң, БЕРСЕН генә сайлап алып җавап языгыз. Автор позициясен ачыгыз, әсәр текстына таянып, үз фикерегезне дә дәлилләгез.** |

17.1. Р.Фәйзуллинның «Җаныңның ваклыгын...» шигырен тыңлагыз һәм лирик геройга нинди сыйфатлар хас булуын языгыз.

17.2. Р.Аймәтнең лирик героена нинди сыйфатлар хас?

## ҖАВАПЛАР

### Ачык һәм ябык тестларга җаваплар

| Биремнең саны | Җавабы |
|---|---|
| 1 | 1 |
| 2 | 1 |
| 3 | 3 |
| 4 | 1 |
| 5 | ЛИРИК ГЕРОЙ |
| 6 | 231 |
| 7 | 312 |
| 8 | ЛИРИКА |
| 9 | 1 |
| 10 | 1 |
| 11 | 1 |
| 12 | 2 |
| 13 | ОСТАЗБИКӘ |
| 14 | 231 |
| 15 | 123 |
| 16 | ҖАН БАЕВИЧ |

### Киңәйтелгән җавапларны (5-10 җөмлә күләмендә) бәяләү критерийлары

5-10 җөмлә күләмендәге киңәйтелгән җавапны таләп итә торган бирем. Җавапка билгеләнгән күләм шартлы, ул сорауның катлаулылыгына һәм эчтәлегенә бәйле. Укучы сорауга эчтәлеге ягыннан тулы җавап язарга, әмма үз җавабын мөмкин булган кадәр кыска формалаштырырга тиеш.

| Критерий | Балл |
|---|---|
| **1. Фикер тирәнлеге һәм җавапның дәлилләнгән булуы** | |
| а) укучы биремнең үзенчәлегенә төшенгән: сорауны аңлап җавап биргән, автор позициясен ачкан, үз фикерен дәлилләгән, фактик хаталар юк / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштырган | **2** |
| б) укучы сорауга җавап бирә, ләкин җавабын нигезләп бетерә алмый / яки җавабын әсәрнең кыскача эчтәлеген сөйләү белән генә чикли, җавап хаталы һәм төгәл түгел / яки җавапта бер-ике фактик хата күзәтелә / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштырып җиткермәгән | **1** |
| в) укучы сорауга бөтенләй җавап бирмәгән / яки эчтәлеге ягыннан сорауга туры килми торган җавапны язган / яки 3 һәм аннан да күбрәк фактик хата ясалган / аудиотекстны аңлап, кабул итеп, җавабын дөрес формалаштыра алмаган | **0** |
| **3. Җавапның сөйләм нормаларына туры килүе** | |
| а) Җавапта бер генә сөйләм хатасы бар | **1** |
| б) җавапта сөйләм хаталары бердән артык | **0** |
| **Иң югары балл** | **3** |

***Промежуточная аттестация: дифференцированный зачёт – Каждый студент защищает презентацию на интересующуюся тему, используя изученные темы.***